| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2021 Казан ш. № 526-23/э-2021

«Энерго - Про» акционерлык җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2022-2026 елларга индивидуаль тарифлар билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя куюү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең "Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Энерго - Про» акционерлык җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, 2022 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр 2022-2026 елларга календарь буенча бүленгән индивидуаль тарифлар билгеләргә.

2. Үзенә карата электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Энерго - Про» акционерлык җәмгыяте өчен, шушы

карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2022-2026 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары билгеләргә.

3. Әлеге карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, «Энерго - Про» акционерлык җәмгыятенең 2022-2026 еллар кирәкле тулай керемен (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәисе А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2021 № 523-23/э-2021
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә «Энерго-Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2022 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмаларының исеме | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Энерго-Про» акционерлык җәмгыяте – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2022 | 279 682,50 | 297,85 | 1,00637 | 279 682,50 | 297,85 | 1,00637 |
| | | 2023 | 283 390,92 | 309,76 | 1,02768 | 283 390,92 | 309,76 | 1,02768 |
| | | 2024 | 287 170,54 | 322,15 | 1,04964 | 287 170,54 | 322,15 | 1,04964 |
| | | 2025 | 291 022,73 | 335,04 | 1,07229 | 291 022,73 | 335,04 | 1,07229 |
| | | 2026 | 294 948,88 | 348,44 | 1,09563 | 294 948,88 | 348,44 | 1,09563 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2021 № 526-23/э-2021
карарына 2 нче кушымта

Үзенә карата электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген озак сроклы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «Энерго-Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2022-2026 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Татарстан Республикасындагы челтәр оешмасының исеме | Ел | Контрольдәге чыгымнарның база дәрәҗәсе | Контрольдә тотылырга тиешле чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Активлар саны буенча контрольдәге чыгымнарның сыгылмалылык коэффициенты | Электр челтәрләре аша тапшырганда электр энергиясен югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача дәвамлылыгы күрсәткече | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача ешлыгы күрсәткече | Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфат дәрәҗәсе күрсәткече |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | млн. сум | % | % | % | сәгать | данә | |
| 1 | «Энерго-Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2022 | 14 843,49 | 2% | 75 | 9,11 | 0,82910 | 0,12755 | 1 |
| | | 2023 | Х | 2% | 75 | Х | 0,81666 | 0,12564 | 1 |
| | | 2024 | Х | 2% | 75 | Х | 0,80441 | 0,12375 | 1 |
| | | 2025 | Х | 2% | 75 | Х | 0,79235 | 0,12190 | 1 |
| | | 2026 | Х | 2% | 75 | Х | 0,78046 | 0,12007 | 1 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2021 № 526-23/э-2021
карарына 3 нче кушымта

«Энерго-Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2022-2026 елларга кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасындагы челтәр оешмасының исеме | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Энерго-Про» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2022 | 26 924,15 |
| | | 2023 | 27 281,15 |
| | | 2024 | 27 645,00 |
| | | 2025 | 28 015,84 |
| | | 2026 | 28 393,80 |

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге